подвижный, любознательный шакирд, он уважает старших, жалеет и помогает бедным. В то же время он любит свой родной язык и культуру. По Г. Тукаю, любовь к родине начинается с колыбельной матери, с пения соловья в саду и, конечно, с первых школьных учебников на родном языке.

**Литература**


1. Абдулхакова А.Р. Татарская детская книга начала XX века: 1901 – 1917 гг.: дис… канд. филол. наук. – Казань, 1998. – 261 с.
2. Бөдәйли М. Псевдонимнар турында берничә сүз. ЛФК СККБ, с. б. 2501 т., 180 б.
3. Валеев М.Х. Татарская детская Литература и детская книга конца XX века (1980 – 2000 гг.): дисс. в виде научного доклада…канд. филол. наук. – Казань, 2002. – 48 с.
4. Габбасова К.А. Изображение природы в поэзии Габдуллы Тукая. – Казань: Ин-т Истории АН РТ, 2010. – 130 б.
5. Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Г. Тукая. – Казань: Изд-во Казан. универ., 1964. – 83 б.
6. Нигъматзянова А.Р. Опыт издания детской книги в начале XX века и его значение для современного национального книгоиздания // Книга и библиотека в контексте национальной культуры. – Казань: Медицина, 1995. – С. 19 – 26.
7. Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Татарская «Алифба». национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX-начало XX вв). – М.: НПБ им. К.Д. Ушинского, 2014. – 260 с.
8. Тукай Г. Мияубикә. – Казан: Лито-типог. И.Н. Харитонова, 1911. – 23 б.
9. Тукай Г. Диван. – Казан: Электро-типог. Л.П. Антонова, 1913. – 37 б.
10. Тукай Г. Балалар күңеле. – Казан: Электро-типог. «Мааариф», 1914. – 31 б.
11. Тукай Г. Избранное. – Казань: Магариф, 2006. – 239 б.
12. Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: Электро-типог. «Үрнәк», 1911. – 441 б.
13. Тукай Г. Юаныч. – Казан: Лито-типог. И.Н. Харитонова, 1908. – 15 б.
14. Тукай Г. Шүрәле. – Казан: Электро-типог. «Үрнәк», 1909. – 48 б.
15. Тукай Г. Балалар өчен шигырьләр. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 77 б.
16. Тукай Г. Яшен ташлары. 1 нче җөз.– Казан: Электро-типог. «Умуд», 1911. – 23 б.; 2 нче җөз. – 24 б.
17. Тукай Г. Яшен ташлары. 1 нче җөз. – Казан: Электро-типог. «Маариф» , е. ю. – 23 б.
18. Тукай Г. Халык моңнары. – Казан: Миллэт, 1910. – 24 б.
19. Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 341 с.
20. Хайруллина Н.М. Развитие учебной литературы для татарских школ дореволюционного периода (вторая половина XIX – начало XX вв.): автореф. …канд. пед. наук. – Казань, 1986. – 18 с.



**Гыйлаҗев Таһир Шәмсегали улы,**

*филол. фән.канд., татар әдәбияты кафедрасы доценты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты,*
*Казан, Татарстан Республикасы, Россия*
*e-mail: tgilazov@bk.ru*



УДК 821.512.145


# ҖАМАЛ ВӘЛИДИ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕНДӘ ГАЯЗ ИСХАКЫЙ

# ГАЯЗ ИСХАКИ В ЛИТЕРАТУРНОЙ КРИТИКЕ ДЖАМАЛА ВАЛИДИ

# GAYAZ ISKHAKI IN ZHAMAL VALIDI'S CRITICAL ESSAYS


**Аннотация.** В статье анализируется литературно-эстетическое и общественно-философское осмысление Джамалом Валиди творчества и личности Гаяза Исхаки. Особое внимание уделяется принципам и методам освоения духовного наследия писателя. Дж. Валиди считает Г.Исхаки зачинателем и основателем новой реалистической литературы, им оценивается тесная взаимосвязь его литературных произведений как с общенациональными интересами и стремлениями, так и с общественно-политическими обстоятельствами.



**Ключевые слова:** татарская литература, литературно-историческая концепция, национальный, общественный, нация, объективное воспроизведение действительности, образ.



**Abstract.** The article is devoted to social, philosophical and aesthetic consideration of works by Gayaz Iskhaki, which were analyzed in Zhamal Validi's critical essays. The author introduces the principles of estimating

the heritage of the writer created by Zhamal Validi. The scientist presented Gayaz Iskhaki as a founder of the realistic literature, examined his work in connection with both nation ambitions and national life, and defined the writes role in Tatar literature and universal value

**Keywords:** Tatar literature, literary-historical concepton, national, social, nation, the truth of life, thought, description.

XX йөз башында татар әдәби тәнкыйтен һәм гыйльми-нәзари фикерен формалаштыруга һәм үстерүгә зур өлеш керткән Җ.Вәлидинең бер төркем мәкаләләре Гаяз Исхакый иҗатын тикшерүгә багышланган. Тирән анализ белән аерылып торган бу язмаларда галимнең әдәби барышны өйрәнү һәм бәяләүнең әдәби-тарихи концепциясе ачык чагыла. Әдәби портрет шәкелендә язылып, Г.Исхакыйның беренче әсәрләреннән алып 1913 елга кадәр әдәби иҗатын тикшергән "Гаяз әфәнде" (1913) мәкаләсенең башлам өлешендә автор дедуктив юл белән: "Гаяз! Бу исем хәзер, һич шөбһәсез, татар әдәбияты, татар поэзиясенең мәркәзендә тора" [1, б. 217], – дип яза. Һәм алга таба язучы иҗатының "махсус характерларын" ачу аша шушы нәтиҗәсен дәлилләүгә күчә. Бу процесста Җ.Вәлиди "Татар әдәбияты барышы" (1912) хезмәтендәге методологик концепциясенә таяна [3, б. 206-207]. Галим язучының "тормышның төрле җирләрендә таркалган вә һәр көннең вагы-төягенә күмелгән характерларны бер җиргә җыеп" [1, б. 218] гомумиләштерү юлы белән типлар, тасвирлар тудыру аша тормышны дөрес, объектив, ягъни "барлыкны туры"сурәтләвен билгели. Һәм бу принцип мәкалә авторы тарафыннан "шагыйрьлек вә сәнгатькярлекнең иң мөһим шарты" буларак билгеләнә. "Ул тормышка, барлыкка бер хыял аркылы, аяте хәдис яки бер риваять аркылы, бер мәгълүм гарыз (аңлату) вә хирыс аркылы карамый, бәлки тугрыдын-туры карыйдыр" [1, б. 218].

Җ.Вәлиди Г.Исхакый әсәрләренең идея эчтәлегендә һәм шәкелендәге сыйфади яңарышларны татар халкы тормышындагы һәм иҗтимагый аңындагы үзгәрешләр, мохит белән сәбәпле бәйләнештә күзаллый: "Димәк ки, һичбер истигъдад (сәләт) мохитеннән узып эш кыла алмый, һичбер әдип, һичбер шагыйрь халкының даирәи фикриясе хөдүденнән (фикер даирәсе чикләреннән) чыгып, ул халык әдибе, шагыйре була алмый. Ул халкы илә берлектә үсә, берлектә тәрәкъкый итә"[1, б. 220].

"Гаяз әфәндедә без үз халкы илә берлектә үскән, берлектә үсмәктә булган бер халык әдибе күрәмез" [1, б. 220]. Татар халкының аңын мәгърифәтчелек идеяләре, әдәп-әхлак мәсьәләләре биләгән чорда Гаяз Исхакый да "әхлакчы". Аның "Тәгаллемдә сәгадәт" (1997), "Бай угылы" (1903), "Кәләпүшче кыз" (1900) әсәрләрендә типлар юклыгы, түбән сурәтлелек билгеләнеп, күзгә күренеп торган үгет-нәсыйхәт, вәгазь күрсәтелә. Автор Исхакыйның "гаять куәтле хис вә һәяҗан илә кызган фикерләр" белән язылган программ характердагы "Ике йөз елдан соң инкыйраз" (1902-1904) повестеның темасын "киләчәгемезнең фаҗигъ бер инкыйраз илә тәмам булган ике йөз еллык хасталыгыны тасвир итү" дә билгели. Тәнкыйтьче әсәрдә иҗтимагый-рухи һәм мәдәни яктан артта калган татар тормышының дөрес сурәтләнешен ассызыклый. Җәгъфәр образында исә авторның милли идеалы, өмете гәүдәләнеш тапкан дигән карашта тора: "Җәгъфәр үзе дә гади кеше түгел, бәлки шул Болгарның хыялый тимсале (сурәте). Гаяз әфәнде гүяки шушы яннарыннан тир исе килә торган, җеп мыеклы, тәгассыб вә наданлык капчыгы булган татарларны җисмән үтереп бетерә дә, милләтенең тәкъдисе иттеге (изге дип ышанган) рухыннан әлегә кадәр күренмәгән, шундай Җәгъфәр исемле бер сурәт ясый Аның авызыннан, шул мөкатдәс рухны томалап торган әләге тәгассыб калыпларына ләгънәтләр яудыра, фөрьядлар итә, ниһаять ул рух та сүнә" [1, б. 226].

Алга таба Гаяз Исхакый иҗаты сыйфади яңарыш ноктасыннан анализлана. Тәнкыйтьче язучы әсәрләрен Аурупа һәм рус әдәбият белеменең культура-тарих мәктәбе йогынтысында барлыкка килгән "җәмгыятьче"ләр мәктәбе" (Д.Заһидуллина) концепциясе һәм мәдәни бәйләнышлар ассызыгында тикшерә. "Теләнче кыз" романында башка әсәрләрдән аермалы буларак "зыялы яшь татар тибы" аша мөһим иҗтимагый-милли проблемалар күтәрелү ассызыкланып, әдип каләменә рус реалистлары Толстой, Достоевский һәм Тургенев йогынтысы күрсәтелә.

Җ Вәлиди карашынча, Г.Исхакыйның "танчы"лык вакыты әдәби эшчәнлек ягыннан нәтиҗәле булмый. Алга таба тәнкыйтьче язучы иҗатында 1910 елдан башланып киткән яңа чорны билгеләп, аның идея-эстетик сыйфатлары турында сүз алып бара башлый. Тәнкыйтьче "шагыйрьгә табигать вә икълимнең (климатның) тәэсире барлыгын" таныган хәлдә, бу елларда Төркиядә яшәгән мөхәррир Исхакыйга Истамбулның гүзәллеге, табигате, һава-суларының йогынты ясамавын, киресенчә аның иҗатының халыкчанлык һәм тормышчанлык ягыннан тагын да югарырак күтәрелүен билгели. 1910 еллар татар эстетик-фәлсәфи фикерендә зур бәхәсләр уяткан "фәлсәфә һәм әхлак, шигырь һәм әдәбият", алар арасында мөнәсәбәт проблемасына туктала. "Гакыл үзенең иң зур куәт вә тәэсирене болар аркылы күрсәтә. Фәлсәфә вә әхлак шигърияте илә кызыктырып үзенә җәлеп итә. Шулай ук шигырьдә фәлсәфи вә әхлакыйлыгы илә үзен дә уйлата вә төшендерә" [1, б. 229]. Автор "фикер вә тасвир бөркетенең ике канаты" булган бу ике күренеш арасында бәйләнеш барлыгын таныса да, табигатьләре белән үзгә фәлсәфә белән "шигырь", әхлак белән нәфис әдәбият арасында каршылык барлыгын билгели. Әдәби мәйданга чыккан Гаяз Исхакыйның соңгы әсәрләре татар әдәби тәнкыйтендә "шигырь" һәм әхлакның бер-берсенә мөнәсәбәте проблемасын кискенләштереп җибәрә.

Җ.Вәлиди "әдәбият дигән нәрсә хакыйкать, фазыйләт (күркәмлек), вә гүзәллек намунәсе (үрнәге)" [1,

б. 231] дигән карашны яклаган М.Бигиевкә “начарлыкны яраттырырлык итеп түгел, бәлки нәфрәт иттерерлек итеп тасвир иткән” [1, б. 223] Исхакыйны каршы куя һәм шуның белән әдәбиятның тормышчанлыгын, милләткә “файда”лылыгын [5, б., 181], әдәбият-сәнгатьтә әхлакый һәм иҗтимагый проблемалар чагылу мөмкинлеген яклый: “Минемчә, Гаяз әфәнде “сәнгать – сәнгать өчен” диеп белүчеләрдән түгел. Ул сәнгатьне әхлак өчен диеп белә вә аның һәрбер әдәби әсәренә әхлакый вә иҗтимагый бер идея әсас (нигез) була. <  > Гаяз әфәнде – әхлакчы вә уйлаучы иҗтимагый бер әдип” [1, б. 233]. Галим Исхакый рухи мирасының бу асыл хасиятен язучы “табигать вә әхвале рухиясенә” татар тормышының, милли чынбарлыкның йогынтысы, “халкымызының хәзерге тормыш вә әхлагында иҗаби (уңай) идеал булырлык нокталар бик аз булуы” белән сәбәпле бәйләнештә гыйльми күзаллый.

Г.Исхакыйның әдәби җәмәгатьчелектә зур бәхәс уяткан “Мөгаллимә” драмасын Җ.Вәлиди дә игътибарсыз калдырмый. Тәнкыйтьче рецензиядә пьесаның эчтәлеге һәм типларының яңалыгыннан чыгып, әдип иҗаты хакындагы гыйльми күзаллауларын яңа характеристикалар белән тулыландыра. Иң әүвәл ул, язучы геройларының халыкка хезмәт итү, гомумхалык мәхәббәте яссылыгында тасвир ителүләренә нисбәтле, Исхакый яшьләрен “халыкчылык” иҗтимагый хәрәкәте белән бәйләп карый. Билгеле булганча, бу драмада, “Теләнче кызы” романындагы рухи һәм фикри үзгәрешнең соңгы баскычында торган Сәгадәттән аермалы буларак, үзен халыкка, милләткә хезмәт итүгә багышлаган мөгаллимә Фатыйма тибы иҗат ителә. Җ.Вәлиди “Мөгаллимә”дә “народниклыкның яңарак бер шәкелен, романтизм буявына буялган” төрен билгели. Моңа кадәр татар тормышын реалистик формада сурәтләгән Исхакый каләменең бу пьесада әдәби герой күңелендәге психологик кичерешләрне, акыл һәм хис көрәшен тасвирлауга, ягъни романтизмга борылуын күрсәтә. Гаяз Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты хакындагы беренче монографик хезмәт авторы Флүн Мусин да тәнкыйтьченең бу мәсьәләгә игътибар юнәлтүен искәртә: “...тәнкыйтьче милли хәятны рухи яңарту өчен тырышучы бу яңа герой образларының күбрәк автор хыялында тудырылганын да истә тота” [6, б. 90]. “Безнең әдәбиятымыз тормышның азмы-күпме алдына чыгарга, аның “иртәгә”сен тасвир итәргә мәҗбүр була”[1, б. 329], – дип, Җ.Вәлиди милли әдәбиятның романтизм сукмагына чыгуын дәлилли.

Җ.Вәлиди 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң илдә урнашкан яңа социаль-иҗтимагый һәм мәдәни шартларда да үзенең әдәби хәрәкәтне тикшерү методологиясеннән баш тартмый. 1922 елда җәмәгать һәм дин эшлеклесе Габдерәшит Ибраһимовның үлеме белән бәйле ялгыш фактка нисбәтле, Г.Ибраһимов белән ике арада башланып киткән әдәби бәхәстә, идеологик һәм сәяси ориентирлар үзгәрүгә карамастан, матур әдәбиятның фикри-мәгънәви кыйммәтен, сәнгать әсәренең хосусый үсеш кануннарын яклау юлына баса [4, б. 87]. Шул вакытта хөкем сөргән “буржуаз әдәбият” концепиясенә каршы чыгып, XX гасыр башында иҗат иткән Гаяз Исхакый әсәрләренең сәнгати кыйммәтен һәм гомумкешелек әһәмиятен яклый. Галимнең рус телендә басылган “Очерк истории образованности и литературы поволжских татар (до революции 1917 года)” (1923) дигән фундаменталь хезмәтендә татар иҗтимагый фикере тарихы яктыртылу белән бергә, милли әдәбият үсеше, аның күренекле вәкилләренең, шул исәптән Г.Исхакый әдәби эшчәнлекләренең төп сыйфатларын ачуга зур игътибар бирелә. “XX гасыр башында туып килүче татар әдәбияты горизонтында Гаяз Исхакый кебек зур көч барлыкка килә” [2, б. 92], – дип яза Җ.Вәлиди.

Димәк, татар әдәбият белемендә әдәби барышны тикшерү һәм анализлау, әдәби әсәрне бәяләү юнәлешендә үз әдәби-тарихи концепциясен формалаштырган Җ.Вәлиди Гаяз Исхакый иҗатын татар халкының иҗтимагый-рухи яңарышы һәм милли сүз сәнгатенең үсеш закончалыклары контекстында карый һәм шул яссылыкта язучы каләменең табигатен, асыл хасиятләрен һәм әдәбият мәйданында индивидуальлеген билгели.

**Әдәбият**


1. Вәлиди Җамал. Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – 624 б.
2. Валидов Д. Очерки истории образованности и литертуры поволжских татар (до революции 1917 года). Вып.1. – Москва-Петроград, 1923. – 106 с.
3. Гилазов Т.Ш. Вклад Джамала Валиди в историю татарской литературной мысли // Филология и культура. Philology and Culture. – 2015. – № 4 (42). – С. 206-209.
4. Гыйлаҗев Т.Ш. 20-30 – еллар татар әдәби тәнкыйте үсешендә төп тенденцияләр (метод һәм герой мәсьәләләре): Филол.ф-ре канд. дигән гыйльми дәрәҗәгә дәгъва итүче дисс. – Казан, 1991. – 225 б.
5. Заһидуллина Д.Ф. әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.
6. Мусин Ф. Гаяз Исхакый (Тормышы һәм эшчәнлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 191 б.